**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от ______________ 16.02.2024 № ПР-32 № _______

**«Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча Бердәм комиссия турындагы нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 5 апрелендәге ПР-65 номерлы Башкарма комитет җитәкчесе карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, бюджет һәм бюджеттан тыш средстволардан нәтиҗәле файдалану, намуслы конкуренцияне үстерү, муниципаль ихтыяҗлар өчен заказларны урнаштырганда хәбәрдарлык һәм үтә күренмәлелекне тәэмин итү максатларында, кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 05 апрелендәге ПР-65 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәреш кертергә. «Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча Бердәм комиссия турындагы нигезләмәне раслау хакында", 1 нче кушымта нигезендә, түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча Бердәм комиссия турындагы нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 05 апрелендәге ПР-65 номерлы Башкарма комитет җитәкчесенең карарына үзгәрешләр кертү хакында» 18.05.2018 ел № ПР-107, 23.06.2020 ел № ПР-128, 03.06.2021 ел № ПР-103, 08.02.2022 ел № ПР-26, 24.10.2023 ел № ПР-230 номерлы карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.А. Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
_______________ №_____
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча Бердәм комиссия составы

| | |
|---|---|
| Шакирова Алия Миндыгали кызы | Комиссия рәисе, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар секторы мөдире; |
| Мөхәмәтдинов Илнар Тәлгать улы | Комиссия рәисе урынбасары, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы. |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гарипов Руслан Илус улы | инфраструктур үсеш буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары; |
| Сираева Лиана Рамил кызы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Митрофанова Айгөл Рифкать кызы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар секторы баш белгече; |
| Хузин Рамил Радист улы | "УКС" МУП директоры |